| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПРИКАЗ** | | **БОЕРЫК** |
|---|---|---|
| 08.09.2021 | Казан шәһәре | № 497/2021 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибен раслау турында» 2016 елның 15 мартындагы 63 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларын актуальләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибен раслау турында» 2016 елның 15 мартындагы 63 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «кадрлар бүлеге (Т.А.Толстая)» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Мәгълүматлаштыру бүлегенә (М.Х. Абайдуллин)» сүзләрен «Мәгълүмати-техник хезмәт күрсәтү бүлегенә» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «үземне җаваплы итеп билгелим» сүзләрен «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары А.Л.Штромга йөкләргә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2016 елның 15 мартындагы 63 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы

дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибенә, кушымтада «М.Р.Зариповка» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

3. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л. Штром